

2022 ел башында 95 яшьлек юбилееен хезмәт ветераны, тыл хезмәтчәне Ельники районы Акчеево авылында яшәvче хөрмәтле Мещерова Халифә Хасян кызы билгеләп vтте.
Артта хезмәт, кайчакта авырлыклар белән тулы зур тормыш юлы. Балачагы сугыш белән сугарылган һәм яшьлеге сугыш белән кыздырылган юбилярша исеменә Ватаныбыз Президенты В.В. Путиннан котлау хаты килә. Анда хәзерге стандартлар буенча кvтәрә алмаслык зур хезмәт очен рәхмәт.
Халифә Хасян кызы 1927 елнын 16 гыйнварендә Шехмаметьев Хасян Ибраһим улы белән Асьма Айзәтулла кызы гаиләсендә туган. Халифәдән сон гаиләдә, бер-бер артлы тагы 10 бала туа. Бераз vсә тошкәч, Халифә шул ун балага Апай булып тора һәм сонга кvпсанлы племянникларына да анын ишеге һәрвакыт ачык була.      Хасян кызы Халифәнен балачагы белән яшvсмер еллары коллективизация белән Боек Ватан сугышы елларына туры килә. 1941 елда, әтисе Боек Ватан сугышына киткәндә (әтисе биографиясендә оченче сугыш), Халифәгә барлыгы 13 яшь була. Эшкә яраклы яшьтәге барлык ир-атларны фронтка киткәч, тулы хокуклы колхозчыга әйләнә Халифә: печән чаба, ашлык ура – суга, кыскасы – барлык ир-ат эшен башкарырга туры килгән ана. Ә кырдан сон, икенче смена буларак, кечкенә эне-сенелләрен, картларны карау белән бергә, бакча-йорт эшләрен vтәргә туры килгән ана. Шундый чынбарлык кызны тиз олыгаерга, характер кvрсәтеп авырлыкларны жинәргә ойрәтә.
Эх, яшьлек еллары... Каты арыганлыкка карамастан, кичләре яшьләр бергә жыелып жырлар жырлаганнар, биеп-уйнап вакыт vткәнен дә сизмәгәннәр - тан аткан. Ә иртә таннан тагы эш. Тормыш шулай дәвам иткән.
1943 елны, Халифә, Акчеево авылынын берничә хатын һәм кызлар белән бергә, Мордовиянен Зубово-Поляна районына торф эшкәртергә, урман әзерләргә жибәрәләр. Ә сонышнан Мәскәv олкәсенә кvчерәләр. Иртә таннан агач кисv, куакларын чабу, штабельләргә оюю белән карангыга кадәр башкарганнар. Кон нормасын vтәгәннәргә 100 грамм ипи биргәннәр.
Совет халкынын сугыш кырында һәм тылда кvрсәткән батырлыклары котелгән Жинvне алып килә. Сонрак Шехмаметьевлар гаиләсен тагы бер шатлык котә - әтиләре фронттан кайта. Яралы булса да, ойдә ир-ат коче!
Авырлыкларны жинә-жинә еллар vтә. 1950 елда Халифә Хасян кызы якташы Анвәр Таһир улы Мещеровка кияvгә чыга. Акчеевода алар ой салалар, 4 бала тәрбиялəп vстерәләр. Пенсиягә кадәр Халифә Хасян кызы колхозчы булып эшли. Анын жилкәсендә барлык сезонлы эшләр - печән чабу, бәрәнге жыю, сенаж һәм саламны эскертләv (скирдование) булган. Еш кына, әгәр кемдер сәламәтлеге буенча эшенә чыга алмаса, терлекчеләрне (бозаулар караган) яки савучыларны алмаштырган. Почтада да эшләп алган ул. Акчеево халкыннан сот белән май да жыйган. Мона карамастан, анын йорт хужалыгында тәртип булган, мал-туар да асраган. Доресен әйткәндә, авыл кешесенә 70 торле һонәр белv дә аз. Анын ире, Анвәр Таһир улы да тыл хезмәтчәне. Ул туган авыллары колхозында тракторист, механик, ашлык сортировщигы, кырчылык бригадасы бригадиры булып эшләгән, пилорамда тозелеш материаллары әзерләv белән дә шогыльләнгән. Хәлифә Хасяновна аны 1985 елда жирли. Тырыша-тырыша алар дvрт

кайгыртучан бала тәрбияләп vстергәннәр. Ирен жирләнгәннән сон, Хәлифә Хасян кызы беркайчан да ялгызлык кичермәгән. Балаларынын икесе - улы Шәриф һәм кызы Алия исән. Хәлифә Хасяновнанын яшь нәсел дәвамчысы - оч оныгы һәм бер оныкчыгы бар. Бvген Халифә апа якыннарынын кадер-хормәте белән уратып алынган.
Үзенен олы булуына карамастан, Халифә Хасян кызы Мещерова тәмле-тәмле ашлар пешерә, шул исәптән милли татар ашларын да. Мәсәлән, бик тә тәмле пироглар, пәрәмәчләр, катлама һәм алкалар. Оныклары белән оныкчыкларына кабатланмас матур орнамент белән киемнәр бәйли. Ул якыннарына чиксез мәхәббәт оләшә. Халифә Хасян кызы vзенен киләчәк буыны вәкилләренә кочле хатын-кыз vрнәге; торле яклап булдыклы һәм якыннары очен бик тә соекле.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**